ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалардан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы И.И. Кадамовның Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы һәм «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унөченче утырышында «хөкүмәт сәгате» кысаларында бәян ителгән мәсьәләләрне хәл итү һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча өстәмә чаралар күрергә.

3.2. Гражданнарның торак йортларына (фатирларына) төтен хакында хәбәр итә торган янгын автоном җайланмаларын урнаштыруны финанслау мөмкинлекләрен карарга.

3.3. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге мәсьәләләрне республика башкарма хакимият органнары тарафыннан федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлектә, шул исәптән һәлакәттән коткару штаттан тыш формированиеләрен һәм янгыннан ирекле саклау буенча бүлекчәләрне җәлеп итеп, комплекслы хәл итүне тәэмин итәргә.

3.4. Янгыннарны сүндерүдә турыдан-туры катнашучы затларны бүләкләү, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән ирекле янгын сүндерү командаларына ярдәм күрсәтү мөмкинлеген карарга.

3.5. Халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру тәртибен билгеләргә.

4. Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалардан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә кешеләр күп җыела торган урыннарда һәм кешеләр тәүлек буе була торган объектларда янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлү өлешендә профилактика, тикшерү (күзәтү) чараларын үткәрү эшен көчәйтергә тәкъдим итәргә.

5. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына халыкка янгын куркынычсызлыгы чаралары турында хәбәр итүдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның 3 – 5 пунктларын үтәү барышы турындагы мәгълүматны 2026 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына җибәрергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ · ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 421-VII ДС